ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**2017 елның 19 апреле**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1073**

Зеленодольск муниципаль районы ихтыяҗлары өчен товарлар китерү, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү предметы булган муниципаль контрактларны банк аша уздыруны гамәлгә ашыру очракларын билгеләү турында

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 05 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 35 статьясындагы 2 өлеше, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 20 сентябрендәге 963 номерлы «Контрактларны банк аша уздыруны гамәлгә ашыру турында» 963 номерлы карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы ихтыяҗлары өчен товарлар китерү, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү предметы булган муниципаль контрактларны банк аша уздыруны, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 20 сентябрендәге «Контрактларны банк аша уздыруны гамәлгә ашыру турында» 963 номерлы карары белән расланган Контрактларны банк аша уздыруны гамәлгә ашыру кагыйдәләре белән гамәлгә ашырыла дип билгеләргә:

1.1. контрактны үтәү кысаларында банк тарафыннан исәп-хисаплар мониторингы үткәрүдә төзелгән контрактка карата, әгәр контрактның башлангыч (максималь) бәясе булса, бердәнбер тәэмин итүче (подрядчы, башкаручы) белән контракт бәясе 200 миллион сумнан да ким булмаган күләмдә тәшкил итә;

1.2.,күрсәтелгән контрактны үтәү кысаларында башкарыла торган исәп-хисап мониторингын үткәрүгә өстәмәләр кертүне күздә тоткан контрактны банк аша уздыруга карата, әгәр контрактның башлангыч (максималь) бәясе, бердәнбер тәэмин итүче (подрядчы, башкаручы) белән контракт бәясе 1 млрд.сумнан ким булмаса, банк аша ( банк аша киңәйтелгән уздыру) кабул ителгән товарларның,

эшләрнең (аларның нәтиҗәләренең), хезмәтләрнең контракт шартларына туры килүен тәэмин итәргә мөмкинлек бирә торган башка хезмәтләр күрсәтү.

2. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек белән элемтәләр, массакүләм мәгълүмат чаралары бүлеге башлыгы А. Н. Коршуновка әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының (http://pravo.tatarstan.ru) рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының (http://. zelenodolsk.tatarstan.ru) мәгълүмат сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе А.Х.Сәхибуллин